| | |
|---|---|
| **РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ** |
| **Исполнительный комитет «Балтачевского сельского поселения» Азнакаевского муниципального района** | **Азнакай муниципаль районы «Балтач авыл җирлеге» башкарма комитеты** |
| ул. Молодежная, д 1а , с. Балтачево<br>Азнакаевского муниципального района<br>423302, Тел. (8-292) 4-47-23 | Азнакай муниципаль районы, Балтач авылы,<br>Молодежный урамы, 1а<br>423302, Тел. (8-292) 4-47-23 |

**Балтач авыл җирлеге Башкарма комитеты**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«23» сентябрь 2019 ел №12

Референдум үткәрү инициативасы турында

12.06.2002 ел № 67-ФЗ «Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 15 статьясы, 06.10.2003 ел №131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 22, 56 статьялары, 24.03.2004 ел №23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 17 статьясы, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы « Балтач авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы нигезендә, карар чыгарам:

1. Түбәндәге сорау буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Сез 2020 елда Балтач авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 Төркем инвалидларыннан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, 200 (50%) сум күләмендә 2 группа инвалидлар, 80 яшьтән өлкәнрәк пенсионерлар, күп балалы гаиләләр өчен, 400 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Балтач авылы, Яшьләр урамына, Үзәк урамга, А. Алиш урамына ,8март урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу,ташу, вак таш җәю, эшләр өчен түләү); ;
- Балтач авылында урамнарны яктырту лампалары, яктырткычлар, махсус җиһазлар сатып алу, урнаштыру, килешү буенча эш өчен түләү;;
- Балтач авылында күперне ремонтлау ;
- Балтач авыл мәдәният йорты өчен генератор сатып алу;
- Балтачта «Җиңү көне», «Сабантуй» ,«өлкәннәр көне», «Яңа ел» бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү;
- Балтач авылы юлларын кардан чистарту;
- Балтач авылы территориясендә чүп үләнен чабу;

Балтач авылы зираты территориясендә чүп үләннәрен чабу

ӘЙЕ ЮК».

2. Әлеге карар түбәндәге чаралар аша халыкка игълан ителергә тиеш:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы,Балтач авылы, Яшьлэр урамы,1А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Балтач авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru,

- Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

Башлык: Л.Л.Хэбипов